РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» июля 2022ел г. Альметьевск № 1422

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан район урман массивларында янгыннарны сүндерүдә катнашучы коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 1947 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2022 елның 28 апрелендәге 02-08-02/197-2022 номерлы протестын карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан район урман массивларында янгыннарны сүндерүдә катнашучы коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 декабрендәге 1947 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

11 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә коммерциягә карамаган оешманың башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан коммерциягә карамаган оешманың аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүгә, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы. Шулай ук Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертү буенча коммерциягә карамаган оешманың күрсәтелгән тикшерүләр үткәрүгә тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның ризалыгы турындагы нигезләмәләре»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Зак. № 305-2000

«12. Районның башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары коммерциячел булмаган оешмага субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен, шул исәптән аларны алуга ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыралар».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручи А.Н. Подовалов